

КЛУБ КИРӘК!

Теләче районының Орымширмә авылы халкы гозерен «ВТ» хәбәрчесе тыңлап кайтты

> 3

102 ЯШЬЛЕК ВЕТЕРАН-ХӘЙРИЯЧЕ:

«Мин бит үзем дә сугыш кичердем...»

> 3

ҖАВАП БАР!

Махсус хәрби операциягә килешү төзеп баручыларны нинди сораулар борчый?

> 4

ҖИРСУ

Авылны онытыру өчен дә, ярату өчен дә бер сәбәп җитә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 145 (29112) | Чәршәмбе | 4 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Сәрия
МИФТАХОВА

5 октябрь – Халыкара укытучылар көне

УНИКАЛЬ КЕШЕЛӘР

Әлфинә һәм Гадил Фәйзрахмановлар быелгы уку елында Балтач районында укыта башлаган. «Авыл укытучысы» («Земский учитель») программасында катнашып, бәйгедә җиңгән алар. Билгеле булганча, бу программада катнашучыларга берәр миллион сум акча бирелә. Шәһәр белән авылдагы шартлар аерыламы? Миллион белән генә укытучыны кызыктырып буламы? Укытучылар көне алдыннан «ВТ» хәбәрчесе алар белән шул хакта сөйләште.

Авылга укытучыларны җәлеп итү өчен 2019 елда «Авыл укытучысы» федераль программасы игълан ителгән иде. Республикада бүген 54 миллионер-мөгаллим белем бирә. Ул укытучыларга таләп тә бар: алар авылда биш ел эшләргә тиеш.

Гадил үзе – Балтачтан утыз чакрымдагы Арча районының Носы авылыннан. Аңа – 29 яшь. Хатыны Әлфинә – Казанбаштан. Моңа кадәр Яшел Үзәннең Осиново гимназиясендә белем биргәннәр. Ике авылга да якын дип, Балтачны сайлаганнар. Быел июль аенда яшьләр туй иткән.

Авыл җирлеге өчен табыш дисәң дә була Фәйзрахмановларны. Гадил үзе генә сигез фәннән укыта ала! Башта Арча педагогика көллиятендә башлангыч һәм информатика укытучысы белгечлеген үзләштергән ул. 2014 елны Казанның 17 нче гимназиясенә эшкә урнашып, читтән торып КФУга укырга кергән. Бер ел эшләгәч, армия сафларында хезмәт иткән. Аннан Яшел Үзән районының Осиново гимназиясендә – башта башлангыч сыйныфларны, тора-бара физика-математика укыткан. Ике ел магистратурада тарих юнәлеше буенча белем алган. 7 ел шахмат түгәрәге алып барган. Казан мәктәбендәге укучыларны, бакчалардагы сабыйларны да шахмат уйнарга өйрәткән. 2014 елда «Безнең яңа укытучы» грантын откан.

Әлфинәгә – 26 яшь. 2017 елда Арча педагогика көллиятен тәмамлап, Осиново гимназиясендә алты ел башлангыч сыйныфларны укыткан. КФУда югары белем алган.

Сан

Республикада **77 мең**нән артык педагогик хезмәткәр исәпләнә. Шуларның **36 мең**нән артыгы – мәктәпләрдә, **21,8 мең**е бакчаларда белем һәм тәрбия бирә. **7 мең**е – өстәмә белем бирү, **11,8 мең**е югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында эшли.

Фәйзрахмановлар гаиләсе «Авыл укытучысы» программасы буенча Балтач урта мәктәбенә укытырга кайткан.

Гадил укытучылыкка 11 ел (!) укыган. Әле тагын укуын аспирантурада да дәвам иткән булыр иде, әгәр кесә ягы калынрак булса. Әмма барысы да акчага килеп төртелгән. «Гади укытучы хезмәт хакына аспирантурада укып булмый. Уку туйдырмый мине. Укытучы һәрвакыт эзләнергә тиеш. Замана баласы белән бергә атламасаң, аның белән уртак тел табып булмый», – ди математика укыткан Гадил.

– Миллион – бүген күп акча түгел. Бер укытучыга гына бирелгәндә, аңа фатир тими. Беренче кертемгә генә ярый. Икеңнеке хет күзгә күренә, – ди ул. – Авылга миллион белән генә кайтарып булмый. Хәзер анда укытырга балалар да юк бит. Кечкенә авыллар бетеп бара. Мәктәп яшәсә, авыл яши, диләр. Тумаган бала белән авыл яшәми. Яшьләр вакытлыча кайтырга мөмкин. Киләчәк булсын өчен, укучы кирәк. Шуңа күрә барлык өлкәләр дә күтәрелергә тиеш. Шәһәрдә дә укытучылар җитми. Анда да программалар булсын. Ун ел үзгәрмәгән хезмәт хакы да үзгәрсен иде. 2014 елда – эшли башлаганда да шул хезмәт хакы иде. Хәзер дә аермасын сизмим.

2023 елның Укытучылар һәм остазлар елы дип игълан ителүе юкка түгел. Укытучыга карата җәмгыятьнең игътибарын арттыруны күздә тота ул. «Укытучыларның илебез өчен керткән хезмәтләре турында күбрәк сөйләргә кирәк», – диде Россия Президенты әлеге елны ачу чарасында.

Федераль Җыенга Юлламасында да Владимир Путин укытучыларның турыдан-туры ил төзелешендә катнашуын әйтте. «Әти-әниләр укытучы турында яхшы яктан гына сөйләсен өчен, мөгаллимнәрнең җәмгыятьтә абруен күтәрергә кирәк», – диде ул.

Укытучылар һәм остазлар елында илдә «Мәгариф» һәм башка проектлар тормышка ашырыла. «Киләчәк укытучысы» проекты кысасында барлык төбәкләрдә педагогларның осталыкларын үстерү үзәкләре ачыла. Бүген илдә шундый 140 үзәк эшли. Педагогик уку йортлары базасында «Кванториум»нар ачылды. Анда мәктәпләрдә, техникум, вузларда белем бирүче укытучылар белемнәрен күтәрә. Ел ахырына кадәр вузлардагы технопарклар саны 33кә җитәчәк. Хәзерге вакытта аларның саны – 20.

Ахыры 2 нче биттә >

Кунак көткәндә

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов БРИКС (Бразилия, Россия, Һиндстан, Кытай, Көньяк Африка берлеге) илләренең спорт уеннарына әзерләнү һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитеты рәистәше урынбасары итеп билгеләнде. Оештыру комитеты составы Россия Хөкүмәте боерыгы белән расланган. Комитетның рәистәшләре – Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко һәм Президент ярдәмчесе Игорь Левитин. Рөстәм Миңнехановтан тыш, Россия спорт министры Олег Матыцин рәистәш урынбасары булачак.

Оештыру комитеты составына тагын 15 кеше, шул исәптән Татарстан вице-премьеры – Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров һәм спорт министры Владимир Леонов кергән.

Исегезгә төшерәбез: БРИКС илләренең спорт уеннары Казанда киләсе елның 12–23 июнендә узачак.

Бер елга китәләр

Октябрь – декабрь айларында Татарстаннан 3 меңнән артык егетне армия сафларына озату планлаштырыла. Булачак солдатлар гаскәрләргә 16 октябрьдән җибәрелә башлаячак. Хәрби хезмәткә 18 яшьтән 27 яшькә кадәрге егетләр чакырыла. Ә инде чакыру яшен 30га кадәр күтәрү киләсе елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы хәрби комиссары генерал-майор Сергей Погодин әйтүенчә, тегеяки бу егетнең үзе теләгән урында хезмәт итүе сәламәтлегенә, белеме, хәрби-учет белгечлеге буенча әзерлегенә, психологик халәтенә карап тормышка ашырылырга мөмкин. Аның сүзләренә караганда, кайбер егетләр шундук контракт төзү юлы белән хәрби хезмәт узуны сайлый. Контрактны 18 яшьтән төзергә мөмкин.

Сак булыгыз!

Татарстанда коронавирус белән чирләүчеләр саны өчтән бер өлешкә диярлек арткан. COVID-19 таралуга каршы көрәш буенча федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, 25 сентябрьдән 1 октябрьгә кадәр авыру иярткүнең яңа 142 очрагы теркәлгән. Бу – алдагы атнадагыга караганда 30,3 процентка күбрәк. Сырхауларны хастаханәгә салу очраклары да ешайган. Шушы чорда 109 кеше (узган атнадагы белән чагыштырганда 34,5 процентка артык) хастаханәгә эләккән.

Җылы килде

Пәнҗешәмбе – 5 октябрьдә Казанда ягу сезоны башлана. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Искәндәр Гыйниятуллин әйтүенчә, башкалабызның балалар бакчаларына, мәктәпләр һәм хастаханәләренә инде узган атнада ук җылы бирелә башлаган. Социаль өлкәгә караучы 853 оешманың 298е җылытыла инде.

Сентябрь азагы мәгълүматлары буенча, Татарстанның 35 районы җылылык бирү сезонын башлап җибәргән. Күпфатирлы һәр 10 йортның берсе (11%) җылытылган.

Исегезгә төшерәбез: җылылык бирә башлауның тәгаен генә көне юк. Ул кимендә биш көн буе һаваның тәүлеклек уртача температурасы +8 градустан кимрәк торганда кертелә.

Беренче кар көтелә

Атна ахырында Татарстанда суыта. Беренче кар да яварга мөмкин. «Метео» фаразлау үзәге җитәкчесе Александр Шувалов әйтүенчә, атна урталарында республикада чын мәгънәсендә алтын көз саклана. Көннәр кояшлы булачак, термометрның терекөмеш баганасы +15...+17 градуска кадәр күтәреләчәк. Ә менә шимбә көнне, салкын һава агымы үтеп керү сәбәпле, хәлләр үзгәрә. Температураның +9...+12 градуска кадәр төшүе көтелә. Яңгырлар булырга мөмкин.

Шул ук вакытта, белгеч билгеләп үткәнчә, якшәмбедә яки киләсе атна башында республиканың төньяк һәм төньяк-көнчыгыш төбәкләрендә беренче кар төшәргә мөмкин.

Вазгыять һәм гамәл

Туганлык көче

Татарстан белән Үзбәкстан арасында күптәннән тыгыз мөнәсәбәтләр урнашкан. Мәгариф, фән, туризм, мәдәният, техника – бу һәм башка өлкәләрнең һәрберсендә билгеле бер уңышлар бар. Хезмәттәшлекне арттыру, дәвам иттерү мөһим. Бигрәк тә хәзерге вазгыятьтә. Моның өчен ике якның да мөмкинлекләре җитәрлек.

Соңгы арада халыкара сәяси мәйданда ислам дөньясы илләре, элеккеге союздаш республикалар белән хезмәттәшлек итү активлашты. Бүгенге вазгыятьтә әлеге дәүләтләр үзләрен ышанычлы партнер буларак тәкъдим итә.

Алар белән фикер алышырлык вакыйгалар да, хезмәттәшлекне үстерерлек юнәлешләр дә, уртак эшләр дә шактый. Тормышка ашырыла торган проектлар да шәйләнә. Аеруча – Татарстанның. Бу җәһәттән «Татарга тылмач кирәкми» дигән сүзләр дә искә төшә. Илләр арасында дуслык җебен – Татарстан, төгәлрәк әйтсәк, республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов сузып йөри.

Казанны кабат халыкара хезмәттәшлек һәм элемтәләр барлау мәйданы итеп сайладылар. Юкка түгел, билгеле. Алда әйтеп үткән факторлар да моңа йогынты ясый. Бу юлы башкалада Россия һәм Үзбәкстан арасында төбәкара хезмәттәшлекнең өченче форумын уздыру планлаштырыла. Бүгенге вазгыятьтә булган дуслык җепләрен ныгыту, яңа багланышлар табу актуаль.

Сүз уңаеннан, Россия белән Үзбәкстан арасында дипломатик элемтәләр 1992 елда урнашкан иде. Ил Президентының – Үзбәкстанга, Үзбәкстан җитәкчелегенең Россиягә эш сәфәрләре белән еш йөрүләре, килешүләр имзалау, әлбәттә, санлы күрсәткечләрдә дә чагыла. Әйтик, 2022 ел нәтиҗәләре буенча Россия Үзбәкстанның иң зур сәүдә партнеры булып танылды. Икенче урында – Кытай.



tatarstan.ru

Татарстан делегациясе Үзбәкстанга тәүге рәсми эшлекле сәфәре белән 1998 елда бара. Ул чакта Татарстан делегациясен Минтимер Шәймиев җитәкли. 2003 елда Премьер-министр вазыйфасында Рөстәм Миңнеханов та эш сәфәре белән тугандаш республикага сәфәр кыла. 2005 елда Үзбәкстаннан делегация Казанга килә. 2017 елда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстан Президенты белән очраша, эш сәфәре кысасында кайбер килешүләр имзалана. Шуннан соң аралар тагын да якыная диярга була. Бу елның апрелендә Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстанга эш сәфәре белән барып кайтты, «KazanForum» чарасы кысасында Үзбәкстан делегациясе Казанга килде.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Сергей ШОЙГУ,
Россия оборона министры:

Ел башыннан контракт буенча 335 меңнән артык кеше хәрби хезмәткә китте. Сентябрь аенда гына да 50 меңнән артык кеше килешү төзеп, хезмәткә алынды. Уртак эшкә өлешне илнең барлык төбәкләре, зур предприятиеләр, дәүләт корпорацияләре кертә. Хәзер Россия Кораллы Көчләрендә махсус хәрби операцияне дәвам итү өчен кешеләр җитәрлек. Мобилизация үткәрү нияте юк.

(Россия армиясе җитәкчелеге белән селектор киңәшмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ФИЗИК КУЛЬТУРА һӘМ СПОРТ

«Работа.ру» хезмәте белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең спортка мөнәсәбәтен ачыклаган. Баксаң, сораштыруда катнашканнарның 56 проценты эштән соң физик культура белән шөгыльләнергә тели икән.

43% >> йөзү
30% >> залда күнекмәләр ясау
28% >> йога
25% >> бию
11% >> йөгерү, җиңел атлетика



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАЗАРЛАР БАЗАРДАН АЕРЫЛА

Бөтендөнья сәүдә оешмасы башлыгы: «Без дөнья сәүдәсенең фрагментлашуы билгеләрен күрә башладык. Бу тенденция гадәттән тыш куркыныч», – дип белдерде. Әйе, глобаль капитализм үзенең моңа кадәр булган йөзен югалтты. Дәүләтләр бер-берсенә чикләүләр кертә, аерым товарларны сатуны туктата. Ясалма рәвештә икътисадны һәм социаль тормышны җимерү бара. Мариана Маццукато – Италия һәм Америка гражданлыгына ия булган икътисадчы профессор Бөтендөнья икътисад форумында: «Безнең бөтен планетаны вакциналаштыру омтылышыбыз барып чыкмады, климат үзгәрешләре артык абстракт: кешеләр аңларлык түгел; ләкин якынлашып килүче су кризисы һәркем, хәтта балалар да аңларлык», – дигән иде. Чынлап та, су кризисы планетаның күп почмакларында кискенләшә: Әфганстан – Урта Азия, Әфганстан – Иран, Төркия – Гыйрак, Мисыр һәм аның көньяк күршеләре күптән инде дипломатик бәхәсләр алып баралар һәм вазгыять сугыш хәленә якынлаша. Маццукато белдерүе бәла-казаларның махсус оештырылган булуына ишарә итә. Бу хакта без язмас та идек (юләргә санарлар иде), Россиянең Куркынычсызлык Советы секретаре Патрушевның үткән ел ук ясаган рәсми белдерүе бар. «Коронавирус – АКШ галимнәре җимеше», – дип әйткән иде ул. Аның ул фикерен Дәүләт Думасы Рәисе Володин да куәтләде. Автор бу ике дәүләт эшлеклесенең барлык фикерләре белән дә килешеп үк бетми үзе, әмма планетакүләм хаос тудырырга омтылыш ясаучы көчләр бар һәм алар актив. Нефть белән газ кризисы шулар тырышлыгы белән тудырылды, мәсәлән.

Газ базарында кызыклы хәлләр бар. Моңа кадәр махсус рәвештә нефть һәм газ тармагына инвестицияләрне тыйган Англия тармакны үстерү өчен акча бүлеп бирде. Нидерландның Гронинген ятмаларында 1 октябрьдән газ чыгару туктатылды. Евросоюзда иң зур булган бу ятма Нидерланд казнасына йөзләгән миллиард доллар табыш китерә һәм Европа базарындагы газ кытлыгын каплый алачак иде. Әмма ятмадан газ чыгару туктаусыз җир тетрәүләргә китерә.

Нигериядә – иң беренче булып цифрлы валютаны сынап караган илдә – нәтиҗәләр начар. Илнең Үзәк банкы үткәргән тикшерүләр шуны күрсәтә: цифрлы валюта кертү финанс тотрыклылыгына яный. Enaira-ны (цифрлы найра) керткәннән соң, банк депозитлары юкка чыккан һәм табышлары җимерелгән. Шулай ук башка илләргә дә куркыныч яный.

2008–2010 еллар кризисының бер билгесе мәйданга чыгып килә. Ул чакта миллиардерлар үз-үзләренә күпләп кул салган иде. Америка банк холдинг компаниясе «Wells Fargo»ның башкаручы директоры Грег Беккет Делавэрдагы банк офисы тәрәзәсеннән җиргә сикерде. Үткән кризиста бу күренешне «миллиардерлар яңгыры» дип исемләгәннәр иде.

Россиядә

ӘҖӘТ ҺӘМ ВАЛЮТА БАЗАРЫ МӘТӘЛЧЕК АТА

Россиянең финанс базарлары сикәлтәле юлдан баруын дәвам иттерә. Доллар дүшәмбе сәүдәсен 100 сумга 9 тиен тулмыйча тәгәлләде. Сишәмбедә финанс базарлары ачылганда, 100 сумлык чик инде узылган иде. Тотрыклылык төшкә генә керә һәм рәсми сәясәтчеләр хыялында гына яши дигән сүз бу. «Кара алтын» бәясе күтәрелә, Россия нефте «түшәм» бәяне күптән санга сукмый, әмма бер дә әҗере күренми. Бәйсез икътисадчылар әйтүенчә, сумның кыска вакытлы ныгуы күзәтелергә мөмкин, әмма озак сроклы перспективада доллар раллие котылгысыз.

Федераль хөкүмәт бюджет тишеген бер елга 4 триллион сум әҗәткә алып каплауны планлаштыра. Әмма хөкүмәт облигацияләрен бер елга 12 процентган дә түбәнрәк табыш белән алырга хәтта дәүләт банклары да риза түгел. Хөкүмәт 2024 елда – 4,07 триллион сумлык, 2025тә – 4,36 триллион, 2026да 4,86 триллион сумлык ОФЗ (федераль заем облигацияләре) сатарга тели. Әмма үткән кварталда бурыч кәгазьләре сату планы 70 процентка гына үтәлде. Бурычларның кыйммәтләнүе, ягъни облигацияләрне зур процентлар вәгъдә итеп сату сум көчсезләнүенең яңа дулкынын китереп чыгарачак, ди бәйсез белгечләр. Аларның фаразлары көнендә тормышка ашып тора. Сумнар күп басыла, ә резерв валюталары дефицитта. Кытлыкны тышкы сәүдәне милли валюталарга алып бару китереп чыгара. Бәйсез икътисадчылар, валюта базарында теләсә кайсы мизгелдә паника кузгалырга мөмкин, дип тә кисәтә. Үзәк банкка төп ставканы 15 процентка кадәр күтәрергә киңәш итәләр. Икътисадны түнтәрү өчен шул гына җитми. Илдә сәнәгать җитештерүе инде өч айдан артык түбәнәя. Оборона продукциясе җитештерүне ашкын темплар белән арттыру да булышмый. Углеводородлар чыгаруны кискен киметү үз сүзен әйтә.

Сумның зәгыйфьләнүенә нефть продуктларын экспортлауны туктату да өлеш кертә. Вице-премьер Александр Новак бу чараны «беркайчан да күрелмәгән» дип бәяләде.

Казна хәле авыр булса да, илнең бай катлавы – олигархлар череп байый. Ел башыннан аларның тулаем байлыгы 21,129 миллиард долларга арткан. «Лукойл» хуҗаларының берсе Вахит Алекперов, үз капиталына 6,4 миллиард доллар өстәп, аны 21,8 миллиардка җиткергән. Миллиардерлар Леонид Михельсон һәм Владимир Лисин байлык узышында икенче-өченче урыннарны бүлешә. Россиянең дәүләт бурычы быел беренче яртыеллыкта 9,8 процентка үсеп, 25,1 триллион сумга җиткән.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ХӘТЕРЛӘСЕННӘР ӨЧЕН

КАЗАНДА ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫНА ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ АЧЫЛДЫ

tatarstan.ru

Патриот, талант һәм акыл иясе. Казанда Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты Мансур Хәсәновны әнә шул сүзләр белән искә алдылар. Аңа Фәннәр академиясенең төп бинасында истәлек тактасы ачылды.

– Мансур Хәсәновның һөнәри эшчәнлеге гаять бай. Ул озак еллар фәнни-педагогик эшчәнлек алып барды, совет партиясе органнарында эшләде, милли мәгариф, сәламәтлек саклау, фән, мәдәният, физкультура һәм спорт, журналистика үсешенә зур өлеш кертте, – диде тантанада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов.

Мансур Хәсәновның тырышлыгы үзе исән чакта дәүләт һәм фәнни бүләкләр белән бәяләнгән булса, истәлек тактасы ачу исемен мәңгеләштерүгә бер адым булып тора. Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, академия диварларындагы мемориаль такта – галимнең зур хезмәтләрен тануның тагын бер мөһим билгесе, башкарган эшләренә хөрмәт күрсәтү.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Мансур Хәсәновны киңкырлы шәхес буларак телгә алды.

– Ул үз эшенә һәм халыкка хезмәт итүенә тугры булды, мәдәният, фән һәм мәгариф өлкәсендә күп эшләр башкарды, – диде Минтимер Шәймиев. – Республикада беренчеләрдән булып Фәннәр академиясе барлыкка килде. Бу эштә Мансур Хәсәновның өлеше дә зур. Аның абруе безнең республикада гына түгел, ә Россия күләмендәге фәнни киңлектә дә зур роль уйнады.

Фәннәр академиясенең хәзерге җитәкчесе Рифкать Миңнеханов сүзләренчә, истәлек тактасын кую тарихи гаделлекне торгызу булып тора.

– Мансур Хәсәнов тырышлыгы, талант иясе, патриот булуы белән җәмәгатьчелекнең дә, коллегаларының да хөрмәтен яулый алды, – диде ул.

Белешмә өчен

Мансур Хәсәнов – 1992–2006 елларда Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты. 1994–2010 елларда ул Академиянең татар энциклопедиясе институты директоры вазыйфасын башкарды. Мемориаль такта авторы – скульптор, Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Тимофей Тюрин.

Уникаль кешеләр

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Эшләргә теләгән укытучыга шартлар җитәрлек, димәк. Әмма яшьләрне мәктәпләрдә ничек калдырырга соң?

– Яшермим, минем дә мәктәптән китәргә теләгән чаклар булгалады. Ләкин башлаган эшне ташларга яратмыйм. Әти-әни, мәктәп, укытучы бер булып эшләсә, яшьләр калыр иде. Ләкин кыен хәлләр килеп чыкканда, яшь белгечләр терәк тапмый. Шуңа да укытучы булып төпләнмиләр. Беркем дә укыта башлаганда идеаль укытучы була алмый, тәҗрибә туплап кына моңа ирешергә мөмкин, – диде Әлфинә Фәйзрахманова.

Укытучыга хөрмәт булсын өчен, беренче чиратта, әти-әни өйдә укытучы турында начар сүз әйтмәскә тиеш. Әгәр хурлаганны ишетә икән, бала ул укытучыны беркайчан да яратмаячак. Фәйзрахмановлар фикере шундый. «Кешенең күңеле булсын өчен күп кирәкми. Бер җылы сүз дә җитә. Өлкән буынга да игътибар кимемәсен иде. Алар бит гомерләре буе мәктәптә укытканнар», – ди Фәйзрахмановлар.

САБЫРЛЫК ҮРНӘГЕ

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры Илсур ҺАДИУЛЛИНның Халыкара укытучылар көне белән КОТЛАВЫ

Хөрмәтле укытучылар, мәгариф оешмалары хезмәткәрләре, хезмәт ветераннары!

Быелгы ел Укытучылар һәм остазлар елы дип игълан ителгәнгә күрә, безнең һөнәри эшчәнлеккә мөһим дәүләт проектлары һәм үзгәрешләр кертергә туры килде.

Безнең һөнәр үзенчәлекле. Тормыш укытучыга һәрвакыт югары таләпләр куя. Хәзер укытучы профессиональ яктан грамоталы, укытуның яңа чараларына һәм инновацион методикаларына ия булудан тыш, җәмгыятебездәге тирән үзгәрешләрнең асылын аңларга тиеш.

Сезнең һәрберегезгә, хөрмәтле укытучылар, мөгаллимнәр, рәхмәт белдерәсем килә. Балаларга карата битараф булмаганыгыз, сабырлыгыгыз, хезмәт сөючәнлегегез, алдан әйтеп булмый, белеп булмый торган шартларда да сыйфатлы итеп эшли белгәнегез өчен.

Сыйныфка килеп керүгә үк, укытучы үзенең мөнәсәбәте, белеме, таланты белән баланың шәхесе формалашуына зур йогынты ясый. Дәрескә кергәч, сез инде һәр укучының мәктәптәге тормышы белән яши башлыйсыз. Укытучының хезмәт нәтиҗәсен проект күрсәткечләре һәм сроклары белән генә бәяләп булмый, ул һәр укучының язмышы белән тыгыз бәйләнгән.

Сез – уникаль кешеләр. Сез балаларны тәрбиялисез, өйрәтәсез һәм аларга яңадан-яңа офыклар ачасыз.

Сезнең яныгызда һәрвакыт якыннарыгыз, ышанычлы хезмәттәшләрегез, зирәк остазлар, сезне аңлый торган әти-әниләр һәм яраткан укучыларыгыз булсын. Балаларга бүләк иткән җылылык, сезгә аларның олы рәхмәтләре һәм уңышлары булып әйләнеп кайтсын.

Сезгә нык сәламәтлек телим. Бәхетле булыгыз! Бәйрәм белән!

ТУГАНЛЫК КӨЧЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Үзбәкстанга Россиядән металл һәм аннан эшләнгән әйберләр, машина, җиһаз, минераль продуктлар, азык-төлек товарлары һәм авыл хуҗалыгы чималы экспорт товары буларак чыгарыла. Үзбәкстаннан Россиягә исә тукыма һәм аяк киеме, азык-төлек товарлары һәм авыл хуҗалыгы чималы, химия сәнәгате продукциясе, машиналар, җиһазлар һәм транспорт чаралары керә.

Татарстан кысасында караганда, Үзбәкстан территориясендә республиканың шактый проектлары тормышка ашырыла. Гомумән, бу урында Рәис Рөстәм Миңнехановның тырышлыгын аерып әйтергә кирәк. Төбәк җитәкчесенең мондый эшләрдә шәхсән катнашуы – нәтиҗәле эшчәнлекнең дәвамлы булуына бер адым. Моны башкалар да күрә.

Рөстәм Миңнехановның тугандаш республикага эш сәфәре һәрвакыт билгеле бер проектны гамәлгә ашыру белән тәгәлләнә. Рәис сүзләре белән әйтсәк, соңгы 5 елда республиканың Үзбәкстан төбәкләре белән мөнәсәбәтләре ныгыды. КАМАЗ, Татнефть, Химград, Кэр-Холдинг, «Татхимфармпрепараты» һәм башка компанияләр белән хезмәттәшлек алып барыла. Моннан тыш 2022 елның мартында «Чирчик» химия-индустриаль технопаркы ачылды. Җизакта Казан федераль университетының филиалы эшли. Әлегә камиллеккә чикләр юк.

Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев та Татарстан компанияләренең эшчәнлеген югары бәяләвен әйтеп тора. Соңгы очрашуларның берсендә Үзбәкстан җитәкчесе: «Бездә эшләүче Татарстан компанияләренең ярдәмен югары бәялибез. Бу авыр вакытларда без нәтиҗәле сәүдә-икътисадый һәм мәдәни-гуманитар партнерлыкны саклый алдык. Ике яклы хезмәттәшлекнең уңай тәҗрибәсе безнең илләрнең яхшы мөнәсәбәтләрен алга таба үстерүгә ярдәм итәр дип ышанам», – дигән иде.

Кем әйтмешли, авызына бал да май. Үзбәкстанның сәнәгый-икътисадый яктан гына түгел, халык өчен файдалы булырдай юнәлешләрдә дә (мисал өчен – туризм) таянырлык төбәк булуын исәпкә алырга кирәк. Кунакчыллык, сый-хөрмәт белән алар да дан казана.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

Әскәр ГАТИН, тарихчы:

– Хәзерге көндә Үзбәкстан – БДБ илләре арасында актив үсүче дәүләт. Бигрәк тә икътисадый яктан аларда уңай үзгәрешләр күзәтелә. Үзбәкстан алдында хәзер стратегик партнерлар сайлау мәсьәләсе тора. Көнбатыш илләр, Кытай, Россия, Төркия һәм ислам илләре... Әлбәттә, Россия өчен Урта Азия әле дә мөһим төбәк булып тора. Үзбәкстанда да Россия белән элемтәләр ныклы. Шуңа күрә бу тарихи элемтәләрне саклап калырга кирәк. Шул ук вакытта Үзбәкстанны элеккеге яссылыкта файдаланып булмас, чөнки аларның башка илләр белән элемтәләре нык көчәеп бара. Татарстан өчен Үзбәкстан иң әүвәл тугандаш үзбәк халкы белән уртак рухи мирас ягыннан якын. Бу өлкәләрдә бер-беребезгә файдалы хезмәттәшлек өчен бик зур перспективалар бар. Тюркология өлкәсен үстерү зарур. Казандагы тюркология мәктәбе, бигрәк тә тарихи тюркология әлегә бик зәгыйфь булып кала. Бу юнәлештә белгечләребез юк диярлек. Урта Азиядә татар милләтенә бәйле күпсанлы материаллар саклана, шул ук ислам мирасыбыз уртак. Гасырлар дәвамында татар шәкертләре Бохара, Сәмәрканд, Кабул мәдрәсәләренә барып белем эстәгәннәр, совет чорында да Мир-Гарәп мәдрәсәсенә барып укыганнар. Әйтик, Үзбәкстан җитәкчелеге тырышлыгы белән хәзер үз ислам академиясе булдырылды, ул – актив эшли торган уку йорты, аның эш тәҗрибәсен өйрәнергә һәм аның белән актив эшләргә була. Кайчандыр Казанда көчле тарихи мәктәп булган һәм шәркыять белеме белән Казан университеты дан тоткан. Кызганычка, бу юнәлештә университет «аксый», күп белгечләр аннан китте. Ә бит бу юнәлеш перспективалы: Үзбәкстаннан яшьләр безгә укырга килә, алар, монда укып чыккач, тормышка аяк баса һәм белем алган уку йортларының миссиясен үти. Алдынгы илләр үз университетларын күптәннән инде «йомшак көч» буларак куллана. Без дә куллана алабыз.

Камол БАБОХОНОВ, Татарстан үзбәкләре мәдәни автономиясенең яшьләр бүлеге җитәкчесе:

– Татарстан өчен Үзбәкстан чит түгел. Без бар мәгънәдә дә бик якыннар бит. Тугандаш төбәкләр без. Тел ягыннан гына карыйк. Охшашлык сизелә.

Татарстан белән Үзбәкстан электән үк бер-берсе белән бәйләнештә. Милли традицияләр, мәдәни кыйммәтләр дисеңме, сәүдә юлы дисеңме. Ике якта да бер-берсенә тәкъдим итәрдәй нәрсәләр күп. Татарстан да, Үзбәкстан да – икътисадый яктан актив үсештә саналган төбәкләр.

Мәдәни-гуманитар хезмәттәшлекне аеруча үстерергә кирәк дип саныйм. Чөнки, әйтүемчә, уртаклыкларыбыз күп безнең. Икенчедән, сәнәгый яктан эшчәнлек алып бару. Бу юнәлештә көчәергә кирәк. Әйтик, машина төзелеше, югары технологияләр, химия, нефть сәнәгате. Болар бик перспектив юнәлешләр санала.

ИКЕ АРАДАГЫ ТОВАР ӘЙЛӘНЕШЕНЕҢ ТӨП КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ (меӊ доллар)

	2018 ел	2019 ел	2020 ел	2021 ел	2022 ел	2023 елның 1 яртыеллыгы
Тышкы сәүдә әйләнеше	145761,0	194921,0	156484,1	193372,6	290814,3	147730,4
Татарстаннан экспорт	135576,0	175455,0	126977,9	157513,8	218953,7	100628,4
Татарстанга импорт	10184,8	19466,4	29506,2	35858,8	71860,6	47102

Яшьләр тавышын ишетергә кирәк

Яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү, авылларда яшәүчеләрнең сәламәтлеген саклау һәм салада кадрларны үстерү. Киров шәһәрендә Идел буе федераль округы субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару органнары каршындагы Яшьләр парламентлары ассоциациясе утырышында шушы һәм башка мәсьәләләр каралды. Утырышта Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия Президентының округтагы Вәкаләтле вәкиле урынбасары Олег Машковцев, 14 субъектның парламент башлыклары катнашты.

Утырышта яшьләрне тәрбияләү системасын һәм хәрби-ватанпәрвәрлек эшен законнарга салуда төп юнәлешләрнең төбәкләрдә бер үк төрле булырга тиешлеге әйтелде.

Ассоциация утырышында төбәкләрнең яшьләр парламентлары җитәкчеләре авылда яшәүчеләрнең сәламәтлеген саклау мәсьәләләренә аерым тукталып үтте. Яшь парламентчылар фикеренчә, бүген авыл халкының сәламәтлеген саклау проблемасы медицина кадрлары җитмәүгә турыдан-туры бәйле. Ассоциация әгъзалары кайбер конкрет тәкъдимнәр белән дә чыкты. Мәсәлән, авыл медикларына өстәмә социаль ярдәм чаралары, авылда эшләүче яшь эшмәкәрләргә төбәк салым ташламаларын кертү, агросәнәгать комплексы өлкәсендә мәгариф программалары буенча максатчан укытуга квотаны арттыру.

Әйтергә кирәк, авыл яшьләре проблемасының беренче тапкыр гына күтәрелүе түгел инде. Тәүге тапкыр әлеге тема быел май аенда Пермьдә федераль округ субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары каршындагы Яшьләр парламентлары ассоциациясе утырышында яңгырады. Ул чагында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин яшь парламентчыларны авыл яшьләре проблемаларын аерым игътибар үзәгенә алырга, төбәкләрдә авылларны үстерүгә бәйле хәлләрне җентекләп өйрәнергә өндәгән иде. Парламент башлыгы анда авылда туган яшьләрнең, шәһәрдә белем алганнан соң, еш кына туган җирләренә кире кайтмавына борчылу белдерде.

«Авыл яшьләренә игътибар артты, һәм бу хәл сөендерә, – диде ул. – Без, ассоциациянең алдагы утырышында әлеге теманы күтәреп, хакимият органнары игътибарын шушы проблемага җәлеп иттек. Бүген исә башлаган эшне дәвам иттерергә кирәк. Авылларыбызда талантлы яшьләр күп. Алар – безнең терәк».

Фәрит Мөхәммәтшин шулай ук хәзерге вакытта авылның картаюын, асылда илнең барлык төбәкләрендә диярлек авылда яшәүчеләр саны кимүен, шул ук вакытта күпмилләтле халкыбызның иң яхшы традицияләренең, гореф-гадәтләре һәм рухының нәкъ менә шунда сакланып килүен басым ясап әйтте.

«Башка проблемалар да күтәрелде. Ә иң мөһиме – аларны хәл кылу буенча тәкъдимнәр билгеләнде», – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин.

ЙӨРӘК КЕНӘ КАРТАЙМАСЫН!

Өлкәннәр ункөнлеге

Татарстанда яшәүче 967 мең кеше өлкән яшьтә, бу – республика халкының 24,2 проценты дигән сүз. 208 кеше – 187 әби белән 21 бабай 100 һәм аннан да өлкәнрәк яшьтә. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган очрашуда Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сөйләде.

– Республикада өлкәннәргә игътибар зур. Алар өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. «Демография» илкүләм проекты аларның тормышларын яхшыртуга ярдәм итә. Алар социаль яктан кайгыртылган. Үзләренә тиешле ташламалардан файдаланалар. Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр дә дәүләт ярдәмен тоя, – ди министр.

«Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты Россия Президенты Владимир Путин карары белән гамәлгә ашырыла. Әлеге проект кысасында өлкәннәр медицина ярдәме ала, кирәк икән, өйгә килеп булышалар. Пенсиягә чыгучылар «Актив озын гомер» программасы буенча янә актив тормышта яши башлый. «Өченче буын» университетлары, төрле музыка, спорт түгәрәкләренә йөриләр. Өлкәннәрнең күбесе волонтерлар да әле.

Эльмира Зарипова «Демография» илкүләм проекты кысасында Татарстанда башкарылган эшләргә тукталды.

– Республикада 32,1 мең өлкән кешегә социаль хезмәт күрсәтелә. 16,6 мең кешенең өйләренә барып ярдәм итәбез. 2019 елда пилот проект буларак башланган эш иде бу. Ул чакта «Демография» илкүләм проекты кысасында без урын өстендә ятучы кешеләргә ярдәм итә башладык, – ди министр. – Быелдан безнең тәҗрибәне Россия күләмендә куллана башладылар. «Озак вакытлы ярдәм» дип аталган әлеге хезмәтне 6259 кешегә күрсәтәбез.

Министр әйтүенчә, республикада яшәүче әби-бабайларга иң элек игътибар кирәк. Кайчак аларны тыңлау да җитә, ди ул. Ә инде үз җылыңны бирсәң, ул кешене бик бәхетле итәсең. Татарстанда шундый 31 гаилә үзенә өлкән кешене сыендырган.

– Бәйрәм көннәрендә олыларга игътибар зур. Әмма без аларны көн дә сөендерсәк иде, – ди Эльмира Зарипова. – Өлкәннәр декадасында республикада төрле чаралар узачак. Һәр район хакимияте сайтларында «кайнар линия» телефоны номерлары күрсәтелгән. Бушлай юридик һәм хокукый ярдәм күрсәтеләчәк. Мәдәният йортларында исә кинолар, концерт-тамашалар уза. Республиканың 17 районында өлкәннәр бассейнда бушлай йөзә алачак.

Өлкәннәр өчен оештырылган мәдәни чаралар хакында Казан башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова сөйләде.

– Бүгеннән «Йөзьяшәрләр уены» башлана. Анда кешеләр төрле спорт ярышларында көч сынашачак. Май ахырына кадәр район этаплары узар дип торабыз. Аннары инде без иң көчле спортчыны ачыклаячакбыз, – ди Гүзәл Сәгыйтова. – Казанда «Жизнелюб» клублары бик актив эшли. Элек алар 56 булса, быелдан 92гә җитте.

Картаерга ашыкмыйлар, картая да белмиләр. Татарстан пенсионерлары оешмасы рәисе Любовь Мишина шулай ди. Ул сүзен, өлкәннәргә мөмкинлекләр тудырган өчен, республика җитәкчеләренә рәхмәт әйтеп башлады. «Ил җитәкчелегенә, кеше пенсиягә чыккач, яңа сулыш алып яшәсен өчен тырыша. Нинди генә спорт түгәрәкләре юк! Телисең икән, шахмат уйна, телисең икән, суда йөз. Бик рәхәт тормышта яшибез. Россия Президентына, Татарстан Рәисенә рәхмәт», – диде ул.

Сан

Республикада **147 мең** хезмәт ветераны дәүләт ярдәмен ала. Төрле ташламалар алучылар саны **206 мең**гә җитә. **51 мең**гә якын кеше торак-коммуналь хезмәтләр өчен ташламадан куллана.

Любовь Мишина да актив өлкәннәр турында сөйләде.

– Сәламәтлекне саклыйсыгыз килсә, укырга кирәк, – диде ул. – Башны эшләтү гомерне озайта. Спорт исә сәламәтлек өсти. Әле менә Санкт-Петербургтан кайттык. Командада 8 кеше иде. Людмила Токмачева 300 тапкыр идәннән тартылды. 73 яшьлек Тәнзилә Шәйхуллова 77 команда арасында йөзү буенча 3 нче урынны алды. Ялкау булмаска кирәк. Иң мөһиме яшь барса да, йөрәк картаймасын!

Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков, республикада җитәкчеләр өлкәннәр белән кулга-кул тотынып эшли, ди.

– 2013 елда «Ветеранга – ветеран игътибары» дигән акция башлап җибәргән идек. Ул әле дә дәвам итә. Бу чара ялгыз калган олылар өчен оештырылды. Кайчак социаль хезмәткәрнең дә вакыты җитми, ә безнең ветеран оешмасындагы изге күңелле кешеләр башкаларның хәлен белергә вакыт таба. Алар картлар йортларына, интернатларда яшәүчеләр янына да даими барып тора. Үз районында гына түгел, якташлары гомер иткән башка җирләргә дә барып хәл белешеп кайталар, – ди Хәбир Иштирәков.

– Шушы көннәрдә генә Казан Кремлендәге Татарстанның табигый тарих музеенда Татарстан ветераннары һәм пенсионерларының халык иҗаты күргәзмәсе ачылды. Биредә республиканың төрле районнарында яшәүче өлкән яшьтәге кешеләрнең кул эшләре арасында ни генә юк, – дип соклануын белдерде Хәбир Иштирәков. – Бу күргәзмәдә «Татарстан Республикасы халыклары милли мәдәниятләрен һәм традицияләрен саклаучы ветераннар» дип аталган республика конкурсында җиңүчеләрнең эшләре урнаштырылды. Монда белгечләр тарафыннан сайлап алынган 300гә якын эш тәкъдим ителде. Биредә Татарстанның 33 районында яшәүче кешеләр иҗаты белән танышып булачак.

Быел өлкәннәрнең «Балкыш» фестивале оештырыла башлауга – 10 ел. 2013 елда анда 3500 кеше катнашса, хәзер сәхнәгә чыгам дип торучыларның исәбе юк икән.

– Татарстан Рәисе белән сөйләшергә туры килде. Сүз уңаеннан, бу фестиваль хакында әйттем. Рөстәм Миңнеханов, ветераннарга да булышмасак, без нәрсәгә инде, ярдәм итәрбез, диде. Шундый җитәкче булганда, өлкәннәр җырлап-биеп яши әле, – ди Хәбир Иштирәков.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Рузина Сафина

2023 елда **654** ялгыз яшәүче кешене табиблар тикшергән. **65** яшьтән өлкәнрәкләрне район хастаханәләренә алып бару өчен һәр районда махсус машиналар алынган. 2019–2023 елларда барлыгы **249 мең** өлкән кешене табибларга алып барып, медицина тикшеренүе үткәргәннәр.

ВЕТЕРАННАН – ФРОНТКА

102 ЯШЬЛЕК СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ БЕР АЙЛЫК ПЕНСИЯСЕН ХӘРБИЛӘРГӘ КҮЧЕРГӘН

Азнакайда яшәүче 102 яшьлек сугыш ветераны Гайнулла Әюпов бер айлык пенсиясен хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм өчен күчергән. Районның мактаулы гражданинының әлеге гамәле өлкән яшьтәгеләрне сокландырса, яшь буынга үрнәк булып тора.

– Безнең өчен бик матур һәм шул ук вакытта бик көтелмәгән хәл булды ул, – диде Азнакай районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев. – Гайнулла бабай бер айлык пенсиясен тулысы белән гуманитар ярдәм өчен ачылган махсус счетка күчерде.

Гайнулла Әюпов – сугыш ачысын үз җилкәсендә кичереп, Берлинга кадәр барып җиткән ветеран. 1940 елның чатнама суык кышкы бер көнендә ул, солдат шинелен киеп, Ерак Көнчыгышка кузгала. Аларны яу кырына сугыш башлану белән үк җибәрмиләр әле. Бер ел Амур елгасын японнардан саклаганнан соң, машинасында фронтка сугыш өчен кирәкле корал һәм башка кирәк-яраклар ташый башлый.

– Бабам сөйләве буенча, солдатлар фронт өчен кирәк-яракларны төнлә ташыган. Машина фараларындагы яктылыкны күреп, дошманнар ут ача торган булган. Ә кире кайтканда, яралыларны төяп алып чыкканнар. Шуннан соң аларны тылдагы госпитальләргә озата барганнар, – дип искә алды оныгы Радик Хуҗин.

Сугыштагы батырлыклары өчен Гайнулла Әюпов Кызыл Йолдыз ордены, күп медальләр белән бүләкләнгән. Туган якларына исә батыр солдатка 1946 елда әйләнеп кайтырга насыйп була. Озак та узмый, Әнисәсе белән гаилә корып җибәрә. 1953 елда Азнакайда төпләнеп, зур йорт җиткезеп керәләр. Гайнулла бабай тыныч тормышта да яраткан һөнәренә тугрылык саклый: ПАТП оешканның беренче көненнән алып пенсиягә киткәнче машина йөртүче булып эшли. Үзе шаярып әйтүенчә, иң кадерле «йөк» – нефтьчеләрне йөрткән.

Кызганыч, сәламәтлегенә бәйле, Гайнулла бабайның үзе белән сөйләшеп булмады. Тик райондашлары да, оныклары да аның әле бүген дә зиһенле, тормышны яратучан һәм юмор хисле булуын әйтте. Бүген ул балалары, оныклары тәрбиясендә кадерле һәм кирәкле кеше булып гомер итә.

– Бу – бары тик аның үз карары. «Мин бит үзем дә сугыш кичердем, андагы егетләрнең хисләрен бик яхшы аңлыйм. Шуңа күрә ничек булдыра алам, шулай булышам. Бу – минем бурычым», – дип әйтте, – диде Радик Хуҗин бабасының матур үрнәге турында.

Аны турында районда да зур хөрмәт белән сөйләделәр.

– Гайнулла бабай – киң күңелле, җор телле кеше. Гомер юлында авырлыклар күрсә дә, бүгенгә кадәр үсеп килүче буынга үрнәк күрсәтеп яши. Ул – районда шундый озын гомерле бердәнбер сугыш ветераны. Кызганыч, аның яшьтәше Гыйльминур Җәләева бу атнада гына бакыйлыкка күчте. Мондый кешеләребез безнең районда гына түгел, республикада да санаулы гына калып бара. Без аларга җитәрлек күләмдә кадер-хөрмәт күрсәтеп кала алсак иде, дип тырышабыз, – диде Дамир Гыйләҗев.

Без шалтыраткан көнне ул үзе дә әле берничә сәгать элек кенә хәрби операция зонасыннан кайткан иде. Азнакайлылар җыйган гуманитар ярдәмне хәрбиләргә илтеп тапшырган.

– Солдатларга 4 тоннага якын гуманитар ярдәм тапшырып кайттык, – диде ул. – Донецк, Херсон шәһәрләрендә булдым, якташларыбыз, укучыларым белән очрашып, ярдәмне кулларына тапшырдык. Госпитальгә дигән ярдәмне дә алып барып җиткердек. Россия территориясенә кергән яңа төбәкләрдә эш тулы куәтенә бара, хәтта төнлә дә туктап тормыйлар. Кырларда трактор эшли, бар җирне чистарталар, юллар, йортлар төзиләр. Һәркем үз урынында бик кирәк. Без, тылдагылар да, ничек булдыра алабыз, шулай тырышабыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Хат эзеннән

ОРЫМШИРМӘ КЛУБ КӨТӘ

«Безнең Орымширмә авылында 60тан артык йорт бар, 200дән артык кеше яши. Авылда күңелле чаралар оештырырга, авылдашлар белән очрашып сөйләшергә, китапханәгә кереп китап, я булмаса газета укып чыгарга да урын юк. Инде алты ел Теләче җирле оешма җитәкчеләренә мәдәният йорты сорап мөрәҗәгать итәбез. Тик һәр җыенда елдан-елга кичектереп, безне шулай тынычландырып килделәр. Анда да мәдәният йорты турында сүз кузгаткач, Теләче җирлеге җитәкчесе, эш алып барабыз, диде. Тик нәтиҗәсе генә күренми. Авылда клуб кайчан төзелер? Балаларга туп тибәргә заманча урын да булдырылсын иде. Шулай ук яңа зират урыны да кирәк. Безгә шушы мәсьәләләрне хәл итәргә ярдәм итсәгез иде».

Әбугаз ШӘЙДУЛЛИН. Теләче районы Орымширмә авылы

Редакциягә шундый хат килгәч, без юл уңаенда әлеге авылга керергә булдык.

Орымширмә авылы Иске Җөри җирлегенә карый. Өч урамлы авыл бу. Анда 63 йорт бар, 205 кеше рәсми теркәлгән. Авыл үзе төзек, юллары әйбәт. Кибет, клубы булмаса да, фельдшер-акушерлык пункты, башлангыч мәктәбе бар. Шөкер, мәктәбен оптимальләштерү шаукымыннан саклап кала алганнар. «Автокибет» атнага ике тапкыр кирәк-яракларны китерә.

Урамда очраган урта яшьрәкләрдән клуб, балалар мәйданчыгы турында кызыксынгач, «Кирәк инде ул. Әмма бу хакта өлкәннәрдән сорагыз, безнең әле алга таба да эшлисебез бар», – диючеләр дә булды. Безгә хат язган 76 яшьлек Әбугаз Шәйдулинны эзләп таптык. Заманында колхозда тракторчы булып эшләгән. Хатыны Хафизә белән Үзбәкстанда 15 ел яшәп, 1993 елда туган авылларына кайтканнар. Әбугаз абыйны хатыны «писарь» дип шаярта. Авыл халкын борчыган мәсьәләләрне хакимият органнарына җиткереп тора икән.

– Клубыбыз бар иде. Җимерелә башлагач, узган гасырның туксанынчы еллар ахырында сүттеләр. Шул урынга йорт салдылар. Яңасын төзү турында сүз булмады. Соңгы елларда, клуб кирәк дип, районга бер генә тапкыр бармадык. Ышандыралар – һаман юк. Үзара салым акчасын җыйганда, мәчеткә керергә туры килә, – ди Әбугаз абый.

2024 елда клуб булачак, дип ышанып яши алар. Әбугаз абый тәгаенләнгән урынын да күрсәтте. Элек ашханә шунда булган. Яңа клубта гармун тартып күңел ачар, җырлар идек, дип хыяллана ул. Китапханә, балаларга уйнарга берәр бүлмә дә кирәк, ди.

Әбугаз абый әйтүенчә, ике ел элек балалар мәйданчыгы төзи башлаганнар, әмма анысы да ярты юлда калган. Урамда очраган бер абзый сүзгә кушылып: «Малайларга туп тибәргә ике капка да корып куя алмыйлар. Теләсә кайда футбол уйныйлар. Авылда балалар күп бит», – дип зарланды.

Авыл халкын зират мәсьәләсе дә борчый. Хәзергесендә урын бетеп килә икән. Ләхет алганда су да чыга, диештеләр.

Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Раил Мараков әйтүенчә, яңа зират урыны билгеләп куелган. Авылга кергәндә – сул якта. Тик аны ясау өчен Иске Җөри авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү кирәк, эш шуңа тоткарлана икән. Авыл янында дәүләт яки муниципаль милектәге зират өчен резервланган җир участогы юк. Әмма бер шәхси хуҗалык пай җиреннән 1–2 гектар урын бирергә ризалашкан.

– Клуб урыны да билгеләнде, программага кертүне көтәбез. Балалар мәйданчыгы да кирәк. Үзара салым акчасына кечкенә балалар өчен урын эшләп куйдык. Малайлар анда туп тибә. Шунда заманча итеп универсаль мәйданчык ясарга иде исәп. Тик акчасыз булмый, – диде Раил Мараков.

Орымширмә халкының гозерен Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗиповка җиткердек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Клубны федераль программага кертү буенча эш алып барабыз, – диде ул. – 50 урынлы булыр дип хыялланабыз. Безгә күпфункцияле үзәк кирәк. Клуб белән башлангыч мәктәпне бер түбә астына кертергә исәплибез. Ничек килеп чыгар. Авылда яшьләр кала. Шул ук вакытта кеше санына бәйле нормативлар да бар бит. (Норматив буенча 50 урынлы клуб төзү өчен халык саны 250дән ким булмаска тиеш. – **С.М.**) Мин әйтеп кенә төзелә торган булса, бик тиз булыр иде, – диде Нәҗип Хаҗипов.

Авылга спорт мәйданчыгы да кирәк. Бу уңайдан район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Динар Гыйниятуллин Орымширмә авылының чиратта беренче булып торуын әйтте. Тик республикада бу программа әлегә туктатылган. Кабат яңартылган очракта эшне шушы авылдан башлаячаклар.

Теләче районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Давыт Ихсанов белдергәнчә, авылга Теләче үзәге, Караширмә, Иске Җөри авыллары якын, шунда барырга була. «Бүген бөтен кешенең машинасы бар. Театр, спектакльләр куелып тора. Башлангыч мәктәпкә районның күчмә китапханәсе китап укытырга чыга», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Тормышның агы, карасы...

Бүгенге әңгәмәдәшем – виртуаль «авылдаш». Бер тапкыр да очрашканыбыз булмаса да, безне уртак фикерләр, бердәй тормыш кыйммәтләре бер җепкә бәйләп тора. Шигырьләребездәге юл арасындагы уй-хисләрне дә яхшы тоеп алабыз без. Шулай тоела.

Тугыз ел шәһәрдә укыганнан соң (педучилище, пединститут), авыл барыбер үзенә тарта: Зөлфия (исемен үзгәрттем) әти-әнисе янына кайтып китә. Аларның да кыз баланы үзләреннән ерак җибәрәсе килми, өстәвенә гаиләдә бердәнбер бала да бит. Аннары мөгаллим егеткә кияүгә чыга, балалар үстерәләр. Хәзер инде бергәләп шәһәрдән кайткан оныкларны багалар. Аз булса да ана телен өйрәтергә тырышалар...

Авыл тормышының агын да, карасын да яхшы белә ул. Интеллигент саналса да, сарык, сыер малы андый категорияләрне санлап тормый: печәнен дә сорый, вакытында савуны да таләп итә. Хаклы ялга чыккач кына йокым туйды, ди Зөлфия.

«Мин – табигать баласы, аннан илһам алып яшим, дисәм дә була. Кыен була башласа, урман, кырларга чыгып китәм. Беркем беркемгә комачауламый. Кайчакта ялгыз калу да бик кирәк бит ул». Авылның иң зур өстенлеген шунда күрә дустым.

«Нинди ул бүгенге авыл? Бик авыр сорау. Элекке кебек дустанә мөнәсәбәтләр бар микән хәзер? Халык әлегедән күпкә гадирәк, шаянрак, күңеллерәк иде бит. Илдәге вазгыять үзенең эзен нык сала хәзер халыкка, бер-берсеннән читләштерә, хәтта якын туганнар да бер-берсенә шикләнеп карый. Элекке кебек ачыктан-ачык сөйләшү бар микән? Һәркем үз эченә бикләнгән кебек хәзер.

Авылларны саклап калу авыл кешесеннән тормый. Аларны бетерү өстендә кемнәрдер эшли бит һәм бу күптән башланган дип беләм. Безнең тирә-яктагы руслар авылларын ташлап киттеләр. Безнең авылның да киләчәге бар дип булмый, чөнки яшь гаиләләр бөтенләй юк диярлек. Кырык яшьтән түбәне бөтенләй юк дип беләм.

2010 елда 528 кеше яшәгән авылда хәзер 320 тирәсе. Моңа вахтовиклар, студентлар да керә. Икенче елга мәктәп ябыла, дип әйттеләр: бөтен мәктәпкә бер сыйныфлык бала җыела. Медпункт эшли әлегә, пенсиядәге фельдшерны кире чакыртып алдылар, аны алмаштырырга кеше күренми. Ике кибет бар. Анда эшләргә кеше таба алмадылар, тирә-як авыллардан килеп эшлиләр. Ярый хатын-кызлар булдыклы: барысы да рульдә.

Хәзер бөтен тармакта да эшләргә кеше таба алмыйлар дип ишетәбез бит инде: мәктәптә булсын, хастаханәләрдә булсын, кайда да әзерлекле белгечләр җитми. Алга таба ни буласын күз алдына китерү дә куркыныч.

Авылның бүгенгесен агач-куак басып баручы яр буйлары, таулардан чамаларга була инде...»

Күптән игътибар итәм: тормышка тәнкыйди караган кешегә җирдә яшәү авыррак. Ул кимчелекне күп күрә, аның ал күзлекләре күптән салынган. Һәм шундый шартларда да – тирә-юньдәге тәртип сине бөтенләй канәгатьләндермәсә дә, кануннар синең асылыңны юк итәргә тырышса да – гомерне матур итеп уздырасы килә бит. Күпме көч кирәк моңа! Көчне исә төрле кеше төрле чыганактан эзли. Шулай да күп очракта якыннар, балалар, хобби-мавыгулар ямьлегамьле итә кеше тормышын. Дустым да шулай саный.

«Әлегә исәнбез. Балалар да тормышта үз урыннарын таптылар. Баш өстендә якты кояш көлә. Буш вакытымда (эш арасында да) шигырь язам, музыка, җыр тыңлыйм, газета-журнал укыйм. Элек кулдан-кулга йөртеп китап укый идек. Хәзер алай китап уку юк, дисәм дә булса. Интернет бар, үземне кызыксындырган бөтен нәрсәне аннан табам. Әлеге вакытта иң кызыксындырганы – музыка. Вакытында музыкаль белем эләкмәде бит».

Ниләр борчыймы бүген? «Бик күпләр белән уртак борчу бу: тынычлык тизрәк урнашсын иде. Тынычлык булса, бар да үз урынына кайтачак». Аның соңгы вакытларда язылган шигырьләре дә шул хакта. Күпләрдән аермалы буларак, мәгълүматны бик аралап кына, анализлап кына кабул итәргә тырыша ул, һәм кешеләрнең уйларга иренүләренә борчыла. Кеше үзе утырган ботакны үзе чаба бүген, дип саный.

«Хыялга килгәндә, бу яшьтә хыяллар белән түгел, теләкләр белән яшәргә кирәктер инде ул. Шулай да үз өстемдә эшләргә, тормыштан артта калмаска тырышам», – ди дустым.

Лилия ФӘТТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖАВАПСЫЗ СОРАУ ЮК

ТАТАРСТАНДА КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ «КАЙНАР ЛИНИЯ»СЕ НИЧЕК ЭШЛИ?

«Татар-информ» / Дмитрий Шатров

Ярты елга – 26 меңләп шалтырату. 100 шалтыратучының 30ы – хатын-кызлар. Контракт буенча хәрби хезмәт «кайнар линия»сенең Татарстандагы үзәкләрендә эшләүчеләр журналистларга кайбер санлы нәтиҗәләр турында сөйләде. Көнне төнгә ялгап, татарстанлыларның һәр соравына җавап бирүче операторларның эшчәнлеге белән дә танышырга җай чыкты.

«Кайнар линия» ничек эшли? Билгеле булганча, Татарстанда контракт буенча хәрби хезмәткә кагылышлы сорауларга Казан һәм Чаллыда урнашкан контакт үзәкләрендә эшләүче операторлар җавап бирә. Мондый үзәкләр март аеннан бирле эшли, һәм бүгенгәчә барлыгы 26 меңләп шалтырату кабул итәргә өлгергән. Бер операторга көн саен 50–70 мөрәҗәгатькә җавап бирергә туры килә икән.

– Иң еш сораулар: «Контракт төзегәндә нинди документлар кирәк?», «Кая мөрәҗәгать итәсе?», «Контракт буенча хәрби хезмәткә хатын-кызлар бара аламы?» һ.б. Моннан тыш, хәрби хезмәткәрләргә каралган түләүләр буенча да шактый сораулар килә. Безнең операторлар мөрәҗәгать итүчеләргә үзләре җавап бирә, кирәк икән, тиешле хезмәтләр белән тоташтыра, – дип аңлатты Клиентларга хезмәт күрсәтү бүлеге җитәкчесе Наталья Демьянкова.

Операторлар, сорауларга җавап бирер өчен, мәгълүматны махсус базадан таба икән.

– Бүгенгә кадәр без җавап бирә алмаган сорау, без хәл итә алмаган мәсьәлә очрамады. Бердәнбер искәрмә: контракт буенча хәрби хезмәткә китүчеләрнең хәзерге вакытта кайда булуын сораучыларга гына мәгълүмат бирә алмыйбыз. Аларны без Оборона министрлыгы белән тоташтырабыз, – ди Наталья.

1 июньнән экспертлардан гына торучы икенче линия эшли башлаган. 10 оператор-эксперт мөрәҗәгать итүчеләр, аерым алганда, контракт буенча хәрби хезмәткә китәргә карар кылучылар белән алар киткәнче элемтәдә тора.

Контракт буенча хәрби хезмәткә кагылышлы сорауларны 117 номеры буенча шалтыратып бирергә мөмкин. Тулырак мәгълүмат heroes-tatarstan.ru сайтында да бар. Өлешчә мобилизация мәсьәләләре буенча исә 122 номерлы «кайнар линия» эшли.

Кемнәр шалтырата ала? 117 «кайнар линия»сенә контракт буенча хезмәткә кагылышлы соравы булган һәркем шалтырата ала.

– Күпчелек шалтыратуларны Казан, Әлмәт, Чаллыда яшәүче 25–50 яшьлек ир-атлар һәм хатын-кызлардан кабул итәбез. Сүз уңаеннан, 100 ир-атка 30 хатын-кыз туры килә. Хәзерге вакытта хәрби хезмәттә булучыларның туганнары, якыннары да шалтырата ала, – дип аңлатты Наталья Демьянкова.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән турыдан-туры эшләүче оператор **иң еш бирелә торган сораулар** турында сөйләде. Өлкән оператор Наталья ханым Тенькова «кайнар линия» эшли башлаганнан бирле шалтыратулар кабул итә.

– 30 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар еш шалтырата. Күбесенчә контракт төзүнең тәртибен аңлатырга, түләүләр турында мәгълүмат бирергә туры килә. Күпләрне, контракт төзеп, хәрби хезмәткә киткәч, эш урыннары сакланып калу-калмавы борчый. Сакланып кала, дигәч, тынычланалар. 60 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк ир-атлардан да мөрәҗәгатьләрне еш кабул итәргә туры килә. «Мине хәрби хезмәткә алырлармы икән?» – дип борчылалар. Сүз уңаеннан, аларга акча, түләүләр бер дә кызык түгел. Ватанпәрвәрлек күпкә көчлерәк үзләрендә, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Көннең икенче яртысында, йә булмаса ял көннәрендә шалтыратучылар күбрәк икән.

– Без аларга тиешле мәгълүмат кына биреп калмыйча, соңыннан янә хәбәрләшәбез: хәрби комиссариатларга барып җиткәннәрме, тиешле документларын туплап бетерә алганнармы – барысын да белешәбез, – ди Наталья.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Исегезгә төшерәбез: Россиядә Кораллы Көчләргә контракт буенча хәрби хезмәткә алу дәвам итә. Килешү төзегән һәр кешегә бер мәртәбә **195000 сум** акча түлиләр. Ә махсус хәрби операция зонасында айлык түләү **204000 сум**нан башлана.



ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

«МИН АВЫЛДА ЯШИ АЛМАС ИДЕМ»

Уйлы күңел уйлана

Бездән ерак түгел бер авылда яшәүче танышым күптән түгел генә шифаханәдә ял итеп кайтты. Беренче генә баруы иде. Шуңа күрә очрашкач, шифаханә хәлләрен сораштым.

– Бөтенесе дә бик ошады. Урыны да матур, персонал да бик игътибарлы. Дәвалanучылар да ярдәм итәргә генә тора. Беренче тапкыр баргач, башта тәртибен дә белеп бетермисең бит. Бик шикләнеп кенә барган идем, шөкер, гел юньле кешеләр очрады. Әлфия исемле Казан хатыны белән дуслаштык. Шәһәрдә туып-үскән булса да, татарчаны әйбәт белә. Минем авылдан икәнне белгәч: «Ничек яшисез анда? Мин авылда яши алмас идем», – дип кенә аптыратты.

Баксаң, ул авылда бары бер тапкыр булган икән. Кечкенә чагымда әни белән ниндидер туганнарга, бик ерак кечкенә генә авылга барган идек, ди. Җәяүләп, бата-чума барганны хәтерлим, җәй көне булса да, урамнары да саз гына, бер яктан икенче ягына чыга торган түгел иде, ди.

– Авылның андый чагы үткән гасырның сиксәненче елларында ук калды бит инде дияргә иде, – мин әйтәм. «Дидем инде. Безнең тормыш та шәһәрнекеннән калышмый, урамнарыбыз асфальт, өйләрдә, мунчаларда газ, су кергән, чыккан, дидем. Телефонымдагы бөтен фотоларны күрсәтә-күрсәтә сөйләдем. Ул да шаккатты, мин дә бу заманда да авыл турында шулай дип уйлаучы бармы икәнни дип аптырадым. Үзенә алай дип әйтмәдем инде, кунакка чакырдым, обязательно кайтам, дигән булды, нишләр», – ди танышым.

Менә ничә көннәр инде бу сөйләшү баш миендә «әйләнә». Әлеге мәгълүматка әнинең әтисе ягыннан якын туганы Тәскирә апаның гыйбрәтле язмышы өстәлә. Ул мескенкәй дә яшүсмер чагында чыгып киткәннән соң авылга беркайчан да кайтмый. Сәбәбе бик тирәндә була шул: авыл аның хәтерендә ач-ялангач, хәерче булып кына түгел, ятимлек ачысы белән өртелгән җанына нахакка төрмәгә утыртылу фаҗигасе белән дә төзәлмәс яра булып саклана. Үзе махсус урлап кайтып, үзе берничә тапкыр әләкләп (болар ахырдан фаш була), аз гына ашлык белән дә кызның язмышын сындыра үги әнисе. Алты елга төрмәгә утырталар. Аннан гомерлеккә баш авыртуы алып кайтуы да Тәскирә апабызның авылдан җаны өзелүгә тагын бер сәбәп була. Күп еллар үтеп, ул вафат булгач, улы гаиләсе белән кайтып, әнисенең туган авылы, туган нигезе белән танышып китте. Әнисе авыл турында сөйләгәннәрнең киресен күреп, ул чакта улы Айрат та гаҗәпләнгән иде. Башка кыз туганнары авылга әллә ничә кайтып, андагы үзгәрешләрне сөйләсәләр дә, Тәскирә апабыз аларга да ышанмый, никадәр генә кыстасалар да, беркем дә аны авылга алып кайта алмый. Яшүсмер кызның йөрәгендә үпкә-рәнҗеш шулкадәр ачы була шул, бәлки ул әлеге онытырга теләп тә, оныта алмаган хатирәләре тагын да тирәнәюдән куркып та кайтмагандыр, авыл турында сөйләгәннәрне дә тыңлыйсы килмәгәндер.

...Бу яралы язмыш белән «Авылда яши алмас идем» дигән сүзләр арасында бәйләнеш юк кебек тоелса да, кеше күңеле, кеше хәтере белән бәйләп караганда уртаклык зур кебек тоелды миңа. Менә шулар турында күңелдән әлеге язманы «сырлап», бакча казыганда, үз бакчасында малларына ризык пешерүче күршебез Рәдифә, сизенгән кебек: «Гомер үтте инде, бер җиргә бармадык, шушы авыл дип яшәдек», – дип эндәште.

– Бармасак ни... Без башка җирдә яши дә алмыйбыз бит инде.

– Ие шул...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 336

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+